Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

16.07.2024 ел Менделеевск ш. № 256

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коррупциячел хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 13 июнендәге 258-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатыннан Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ

1. Менделеевск муниципаль районы Советының 2013 елның 4 февралендәге 168 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коррупциячел хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында нигезләмә”гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктының 2 нче абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«яллаучының вәкиле булган муниципаль хезмәткәрнең үзенә буйсынган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында билгеле булган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар яллаучының вәкиле булган муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, эштән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора».

1.2. 2.5 пунктының 2 абзацында «яисә «коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13_4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан»сүзләрен өстәргә:

1.3. 1 пунктның 1.3 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дисциплинар җәзаларны куллану һәм бетерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru дәүләт теркәвенә алганнан соң бастырып чыгарырга  һәм "Менделеевск яңалыклары" газетасында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга. www.mendeleevsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылыкны, хокук тәртибен, кеше хокукларын һәм депутат этикасын саклау буенча даими комитетка йөкләргә.

Совет рәисе: Р.И.Беляев